Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге

Богородский авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

«23» апрель, 2023 ел № 4

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге уставы, Богородский авыл җирлегенең 2017 елның 21 августындагы 80 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегендә (2017 елның 14 декабрендәге 94 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 108 номерлы, 2019 елның 2 октябрендәге 156, 2022 елның 12 декабрендәге 62, 2023 елның 31 мартындагы 70 номерлы үзгәрешләре белән) гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәсе белән, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең яшәү шартларына, хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә район халкының хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча җәмәгатьчелек тыңлауларын 2024 елның 26 апреленнән 2024 елның 15 маена кадәр уздырырга (алга таба - Генераль планга үзгәрешләр кертү проекты). Проектның мәгълүмати материаллары:

- территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә;
- җирлекнең җирле әһәмияттәге объектларын планлаштырып урнаштыру картасы;
- торак пунктларның чикләре картасы (шул исәптән төзелә торган торак пунктларның чикләре);
- функциональ зоналар картасы;
- җирлек составына керүче торак пунктлар чикләре турында белешмәләр, Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрын алып бару өчен кулланыла торган координаталар системасында әлеге чикләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге.
- Генераль планны нигезләү материаллары.

2. Генераль планга үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитетына (алга таба текст буенча - җирлек башкарма комитеты) йөкләргә.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

3.1. Генераль планга үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Богородский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең бөтен территориясендә (алга таба - Богородский авыл җирлеге) торак пунктлар өлешендә - Богородский, Гильдеево, Көек, Камыш, Черниково авыллары. Ильинский, Беренче Май поселоклары территориясендә уздырыла.

3.1.1. Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгеләргә:

- Камыш авылы халкы өчен: 2024 елның 14 маенда 11.00 сәгатьтә ФАП янында (422777, ТР, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Камыш ав., Җиләкле ур. 1А й.);

- Беренче Май поселогы халкы өчен: 2024 елның 14 маенда 11.30 сәгатьтә кибет янында (422777, ТР, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Беренче Май пос., Үзәк ур. 18Б й.);

- Гильдеево авылы халкы өчен: 2024 елның 14 маенда 12.00 сәгатьтә кибет янында (422774, ТР, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Гильдеево ав., Югары ур. 44А й.);

- Черниково авылы халкы өчен: 2024 елның 14 маенда 13.00 сәгатьтә торак йорт янында (422772, ТР, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Черниково ав., Яшел ур. 27 й.);

- Көек авылы халкы өчен: 2024 елның 14 маенда 14.00 сәгатьтә балалар бакчасы янында (422773, ТР, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Көек ав., 26 нчы Квартал ур. 3 бина);

- Богородский авылы халкы өчен: 2024 елның 14 маенда 15.00 сәгатьтә авфыл клубы тамаша залында (422774, ТР, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Богородский ав., Үзәк ур. 57Б/1 й.);

- Ильинский поселогы халкы өчен: 2024 елның 14 маенда 16.00 сәгатьтә кибет янында (422777, ТР, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Ильинский ав., Урман ур. 33 й.);

4. Җирлекнең башкарма комитетына:

4.1. «Вперед» («Алга») район газетасында һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүмат бастырып чыгарырга.

4.2. Генераль планга үзгәрешләр кертү проекты экспозициясен Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында https://pestreci.tatarstan.ru/publichnie-slushaniya-20044697.htm «Экспозиция проектов» вкладкасында урнаштырырга, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский ав., Үзәк ур., 57Б/1 й. адресы буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында оештырырга.

Интернет челтәрендә веб - адрес буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында https://pestreci.tatarstan.ru/publichnie-slushaniya-2004697.htm, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында проект белән 2024 елның 6 маеннан 2024 елның 8 маена кадәр, 13.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр урнаштырылган проект материаллары белән экспозициянең бөтен срогы дәвамында тәүлек буе танышырга мөмкин.

4.3. Әлеге карарның 3 пунктында күрсәтелгән тәртип һәм сроклар нигезендә гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

4.4. Генераль планга үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында билгеләнгән тәртиптә бәяләмә әзерләргә һәм бастырып чыгарырга.

5. Гавами тыңлаулар уздыруның бөтен чоры дәвамында гавами тыңлауларда катнашучылар Генераль планга үзгәрешләр кертү проектына кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- язмача яисә электрон документ рәвешендә гавами тыңлаулар оештыручы адресына, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Богородский авылы, Үзәк ур., 57Б/1 й. адресы һәм bog.pes@tatar.ru электрон почтасы буенча җибәрергә;

- Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Богородский авылы, Үзәк ур., 57Б/1 й. адресы буенча проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсендә (журналында) исәпкә алу юлы белән;

- гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында язма яисә телдән формада.

Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кыска формада, мондый тәкъдимнең яисә кисәтүнең төгәл формулировкасы белән бәян ителергә тиеш.

Гавами тыңлауларда катнашучылар идентификация максатларында үзләре турында белешмәләр (фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү (теркәү) урыны адресы - физик затлар өчен; исеме, төп дәүләт теркәве номеры, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен) тапшыралар, мондый белешмәләрне раслый торган документлар кушып.

Тиешле җир кишәрлекләренә һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына һәм (яисә) күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарга хокуклы булган гавами тыңлауларда катнашучылар шулай ук мондый җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналар, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан булган урыннар турында белешмәләр һәм мондый җир кишәрлекләренә, капиталь төзелеш объектларына, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарга хокукларын билгели яисә раслый торган башка документлар тапшыра.

Гавами тыңлауларда катнашучылар тәкъдимнәр яисә искәрмәләр керткәндә «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гавами тыңлауларны оештыручыларга ризалыгын бирәләр.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбов

СОВЕТ БОГОРОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ